**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

V чакырылышның чираттан тыш утырышы
**КАРАРЫ**

«07» июль 2026 ел № 18 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында тапшыру бурычын үтәве (тиешенчә үтәмәве) турында гомумиләштерелгән мәгълүмат урнаштыру тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 25.12.2008 № 273-ФЗ Федераль законы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы Татарстан Республикасының 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ санлы Законы, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында»гы 19.07.2017 ел, № 56-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында тапшыру бурычларын үтәве (тиешенчә үтәмәве) турында гомумиләштерелгән мәгълүмат урнаштыру тәртибе хакында кушымтада бирелә торган нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, регламент һәм җирлекләр советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы Район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Р.М. Якупов
(8-85593) 2-42-05

Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы карарына кушымта
«___» ________2026 ел № 18

Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында тапшыру бурычын үтәве (тиешенчә үтәмәве) турында гомумиләштерелгән мәгълүмат урнаштыру тәртибе хакындагы нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә белән "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 25.12.2008 № 273-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында»гы 19.07.2017 ел, № 56-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның (алга таба - депутатлар) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында 19.07.2017 «Муниципаль вазыйфаны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе турында» № 56-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4 өлешендә каралган белешмәләрне тапшыру бурычын үтәве (тиешенчә үтәмәве) турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (алга таба - рәсми сайт) гомумиләштерелгән мәгълүмат урнаштыру тәртибе билгеләнә.

2. Рәсми сайтта («Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә) мәгълүмат урнаштырыла (мондый мәгълүматта тиешле затны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган шәхси мәгълүматлар һәм тиешле затныкы булган мөлкәтне индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар булмаган очракта):

1) сайланган депутатлар саны;

2) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәгән сайланган депутатлар саны;

3) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын тиешенчә үтәмәгән сайланган депутатлар саны.

3. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында каралган мәгълүматны рәсми сайтта урнаштыру ел саен 20 майга кадәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы көрәш буенча ярдәмчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.